ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 412 от «27» 10 2025 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында ireклелек (волонтерлык) мәсьәләләре буенча Совет төзү турында

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы территориясендә эшчәнлек алып баручы иректе берләшмәләр (волонтерлар) эшчәнлеген үстерү һәм аларга ярдәм итү максатларында Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты

Карар бирә:

1. 1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында иреклелек (волонтерлык) мәсьәләләре буенча Совет төзергә.

2. Расларга:

2.1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында ireклелек (волонтерлык) үсеше мәсьәләләре буенча Совет турында нигезләмә (1 нче кушымта).

2.2. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында ireклеләр (волонтерлар) үсеше мәсьәләләре буенча Совет составы (2 нче кушымта).

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Мамадыш районының http://mamadysh.tatarstan.ru// рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең урынбасары А.М. Ефимовка йөкләргә.

Җитәкче вазифаларны
башкаручы Р.М.Никифоров

0000012977

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Башкарма комитетының
27.10. 2025 ел, № 412
карарына 1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында иреклелек (волонтерлык) үсеше мәсьәләләре буенча Совет турында**
**НИГЕЗЛӘМӘ**

## 1.Гомуми нигезләмәләр

1.1. Иреклелек (волонтерлык) мәсьәләләре буенча Совет (алга таба - Совет) - җирле үзидарә органнарының, иҗтимагый берләшмәләрнең, социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларның, ирекле (волонтерлык) оешмаларның, башка кызыксынган оешмаларның үсештә көчләрен берләштерү максатларында килешенгән эшчәнлеген тәэмин итүче Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы даими эшләүче консультатив орган.

1.2. Совет үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясе һәм Татарстан Республикасы Конституциясе, федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары һәм башка хокукый актлары, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының норматив хокукый актлары һәм әлеге Нигезләмә белән җитәкчелек итә.

## 2. Советның максаты һәм бурычлары

2.1. Советның максаты – иреклелекне (волонтерлыкны) үстерүдә көчләрне туплау һәм Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының иҗтимагый ирекле берләшмәләре эшчәнлеген координацияләү.

2.2. Советның бурычлары:

- Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы җирле үзидарә органнарының иҗтимагый берләшмәләр, социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар, ирекле (волонтерлык) оешмалар һәм башка кызыксынган оешмалар белән хезмәттәшлеген тәэмин итү;
- социаль мәсьәләләрне хәл итүдә ирекле (волонтерлык) оешмаларының һәм волонтерларның ихтыяҗын тәэмин итүче шартлар булдыру;
- иреклелекне киңәйтү һәм ныгыту өчен шартлар тудыру, гамәлдәге оешмаларның эшчәнлегенә ярдәм итү һәм яңа ирекле (волонтерлык) оешмалар барлыкка килү өчен шартлар тудыру, аларның потенциалын арттыруга ярдәм итү;
- ирекле эшчәнлеккә методик, мәгълүмати, консультация ярдәме инфраструктурасын үстерү;
- халыкны ирекле (волонтерлык) эшчәнлек чараларын үткәрүгә җәлеп итү механизмнарын эшләү;
- иреклелек (волонтерлык) өлкәсендә эшчәнлекне җайга салучы Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының хокукый актлары проектлары турында фикер алышу. Кабул

ителгән хокукый актларны һәм хокукны куллану практикасын ирекле (волонтерлык) эшчәнлеген үстерүгә юнәлдерелгән гамәлдәге чараларның нәтиҗәлелеге предметына анализлау..

## 3. Советның хокуклары

3.1. Совет түбәндәгеләргә хокуклы:

3.1.1. Совет компетенциясенә карый торган мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының региональ башкарма хакимият органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан кирәкле документлар һәм белешмәләр соратырга һәм алырга.

3.2. Совет утырышларына Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының җирле үзидарә органнарыннан, иҗтимагый берләшмәләрдән, социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалардан, ирекле (волонтерлык) оешмаларыннан һәм башка кызыксынган оешмалардан вәкилләр чакырырга.

3.3. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының җирле үзидарә органнарына Ирeклелекне (волонтерлыкны) үстерү мәсьәләләре буенча тәкъдимнәр тәкъдим итәргә.

## 4. Советның эш тәртибе

4.1. Совет 12 кешедән тора. Совет составына ирекле (волонтерлык) эшчәнлекне, шул исәптән коммерциячел булмаган оешмаларны, ирекле (волонтерлык) төркемнәр, иҗтимагый берләшмәләр һәм оешмалар, предприятиеләр лидерлары булган Совет рәисе, рәис урынбасары, секретаре һәм Совет әгъзалары керә.

4.2. Совет рәисе булып вазыйфасы буенча Мамадыш муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең мәгариф, социаль өлкә һәм яшьләр сәясәте мәсьәләләрен алып баручы урынбасары тора.

4.3. Совет составы Мамадыш муниципаль районы башкарма комитеты карары белән раслана.

4.4. Совет эшенә Совет рәисе, ә ул булмаганда аның кушуы буенча урынбасары җитәкчелек итә.

4.5. Совет утырышларны кварталга кимендә бер тапкыр уздыра.

4.6. Совет рәисе үз вәкаләтләре кысаларында:

- Совет утырышын уздыру турында карар кабул итә, көн тәртибен билгели;
- Совет кабул иткән карарларның үтәлешен тәэмин итә һәм тикшереп тора;
- Совет әгъзаларына үз компетенциясе чикләрендә йөкләмәләр бирә.

4.7. Совет эше аның утырышларында расланган планнар нигезендә гамәлгә ашырыла.

4.8. Совет утырышы, әгәр анда аның әгъзаларының гомуми санының яртысыннан артыгы катнашса, хокуклы дип санала..

4.9. Көн тәртибе мәсьәләләре буенча материаллар Совет утырышына үз компетенцияләре кысаларында Совет әгъзалары тарафыннан әзерләнә. Материаллар Совет утырышы көненә кадәр өч көннән дә соңга калмыйча Совет секретарена тапшырыла.

4.10. Совет карарлары Совет утырышында катнашучы Совет әгъзаларының күпчелеге тавышы белән кабул ителә һәм Совет утырышы беркетмәсе белән рәсмиләштерелә. Тавышлар тигез булган очракта, Совет утырышында рәислек итүче тавышы хәлиткеч булып тора. Совет карарлары тәкъдим итү характерында.

4.11. Совет утырышы беркетмәсенә Совет утырышында рәис һәм совет секретаре тарафыннан Совет утырышы көненнән алып 5 эш көне эчендә имза салына.

4.12. Совет утырышында түбәндәгеләр күрсәтелә:

- Совет утырышы үткәрү датасы, вакыты һәм урыны;

- Совет утырышының расланган көн тәртибе;
- Совет утырышында катнашучы әгъзаларның һәм чакырылган башка затларның исемнәре һәм вазыйфалары;
- Совет утырышының көн тәртибе мәсьәләләре буенча кабул ителгән карарлар.

4.13. Совет утырышлары беркетмәләре яисә алардан кирәкле өземтәләр Совет секретаре тарафыннан Совет утырышы көненнән алып 5 эш көне эчендә йөкләмәләрне үтәү өчен җаваплы вазыйфаи затларга җибәрелә.

4.14. Совет эшчәнлеген мәгълүмати тәэмин итүне Совет секретаре гамәлгә ашыра.

4.15. Совет эшчәнлеген оештыру-техник тәэмин итүне Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты һәм Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәте, физик культура һәм спорт секторы гамәлгә ашыра.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Башкарма комитетының
27.10. 2025 ел, № 412
карарына 1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында ирекледәр (волонтерлар) үсеше мәсьәләләре буенча Совет составы)**

| | | |
|---|---|---|
| 1. | Ефимов А.М. | – рәис, Мамадыш муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары; |
| 2. | Нургалиев А.М. | – рәис урынбасары, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы «Яшьләр үзәге» МБУ директоры; |
| | Совет әгъзалары: | |
| 3. | Гарифуллин А.А. | – Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башкарма комитетының «Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге» МКУ җитәкчесе; |
| 4. | Габдрахманов И.Н. | – Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәгариф бүлеге» МКУ башлыгы; |
| 5. | Спиридонов С.П. | – Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәдәният бүлеге» МКУ башлыгы; |
| 6. | Сәйфетдинова Р.З. | – Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының "Мечта" МБУ директоры; |
| 7. | Талипова Г.В. | – Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының ветераннар (пенсионерлар) оешмасы советы рәисе; |
| 8. | Ханова С.Н. | – «ТАТМЕДИА» АҖнең “Мамадыш-информ” филиалы баш редакторы- җитәкчесе; |
| 9. | Мубаракшина А.А. | – Татарстан Республикасы хезмәт һәм халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Мамадыш муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге башлыгы (килешү буенча); |
| 10. | Әгъзәмова Э. Р. | – Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында «Надежда» СПДН» ДКУ директоры; |
| 11. | Гарипов Р.З. | – "Мамадыш үзәк район хастаханәсе" ДАССУ баш табибы; |
| 12. | Егоров Н.Н. | – «Мамадыш ПК» ДАҺБУ директоры; |
| 13. | Рылов О.Ю. | – Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының «Беренчеләр хәрәкәте» җирле бүлекчәсе җитәкчесе. |